КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 сентябрь г.Казань № 964

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне

исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри таләпләр бозылу аркасында әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны каплау турында дәгъвалар бирә;»;

унбишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма хакимиятнең федераль органы белән килештереп, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохиттә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яки) әйләнә-тирә мохиттә тупланган зыянны бетерү, һәм (яки) хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яки) киметү буенча башка чараларны гамәлгә ашыру, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларын рациональ файдалану һәм яңадан торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү эшләрен оештыру чаралары планын раслый;»;

3.3.8 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Су кодексының $67^1$ статьясында суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның зыяннарын бетерү буенча каралган чараларны гамәлгә ашыра;»;

4.1 пунктта:

унбишенче абзацта «күрсәтә» сүзен «күрсәтергә» сүзенә алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «күрсәтә» сүзен «күрсәтергә» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә атмосфера һавасын пычрату буенча җыелма исәп-хисапларны (аларны актуальләштерүне кертеп) оештырырга;»;

4.2 пунктның тугызынчы абзацында «һәм аның компонентларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар (бу карарның 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктының бишенче һәм уналтынчы абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

бу карарның 1 пунктындагы сигезенче абзацының гамәлдә булуы 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин